Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында” Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 30 маенда
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 22 декабрь; 2013, 19 гыйнвар, 2 март) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле $1.1^1$ статья өстәргә:
“$1.1^1$ статья. **Әлеге Кодексның җайга салу предметы**

Әлеге Кодекс Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә түбәндәгеләрне билгели:

1) федераль әһәмияткә ия булмаган һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы белән җайга салынмаган мәсьәләләр буенча административ җаваплылыкны, шул исәптән Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларында каралган кагыйдәләрне һәм нормаларны бозган өчен административ җаваплылыкны;

2) әлеге Кодекста каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрнең кем карамагында булуны;

3) әлеге Кодекста каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген.";

2) 2.2 статьяда:

а) беренче өлештә "Татарстан Республикасы" сүзләрен "1. Татарстан Республикасы" сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә "Әлеге" сүзен "2. Әлеге" сүзләренә алмаштырырга, "беренче" сүзен "1" санына алмаштырырга;

3) 2.5 статьяда:

а) беренче өлештә "Татарстан Республикасы" сүзләрен "1. Татарстан Республикасы" сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә "Татарстан Республикасы" сүзләрен "2. Татарстан Республикасы" сүзләренә алмаштырырга;

4) 2.6 статьяда:

а) беренче өлештә "Җирле" сүзен "1. Җирле" сүзләренә алмаштырырга, "өчен" сүзеннән соң ", әлеге Кодексның 2.7, 2.8, 3.2 – 3.7 статьяларында каралган очраклардан тыш," сүзләрен өстәргә;

б) икенче өлештә "Шул ук гамәлләрне" сүзләрен "2. Шул ук гамәлләрне" сүзләренә алмаштырырга;

5) 3.1 статьяда:

а) беренче өлештә "Сирәк" сүзен "1. Сирәк" сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә "Сирәк" сүзен "2. Сирәк" сүзләренә алмаштырырга;

6) 3.2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.2 статья. **Урам сәүдәсен оештыру тәртибен бозу**

1. Әлеге статьяның 3 өлешендә каралган очраклардан тыш, шул максатлар өчен билгеләнмәгән урыннарда сәүдә иткән өчен –

гражданнарга – ике йөз сумнан алып биш йөз сумга кадәр; вазыйфаи затларга – ике мең сумнан алып биш мең сумга кадәр; юридик затларга егерме мең сумнан алып илле мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган өчен –

гражданнарга – бер мең сумнан алып өч мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – ун мең сумнан алып егерме мең сумга кадәр; юридик затларга йөз мең сумнан алып йөз илле мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

3. Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен (схемасын) бозган өчен –

гражданнарга – бер мең сумнан алып өч мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – биш мең сумнан алып ун мең сумга кадәр; юридик затларга алтмыш мең сумнан алып йөз мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

4. Әлеге статьяның 3 өлешендә каралган гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган өчен –

гражданнарга – өч мең сумнан алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – егерме мең сумнан алып утыз мең сумга кадәр; юридик затларга йөз илле мең сумнан алып ике йөз мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.";

7) 3.5 статьяда:

а) беренче өлештә "Элмә" сүзен "1. Элмә" сүзләренә алмаштырырга, татарча текст үзгәрми;

б) икенче өлештә "Шул ук гамәлләрне" сүзләрен "2. Шул ук гамәлләрне" сүзләренә алмаштырырга;

8) 3.6 статьяда:

а) беренче өлештә "Җирлекләр" сүзен "1. Җирлекләр" сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә "Шул ук гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган (гамәл кылмаган) өчен" сүзләрен "2. Шул ук гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган өчен" сүзләренә алмаштырырга;

9) 3.8 статьяда:

а) беренче өлештә "Төнлә" сүзен "1. Төнлә" сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә "Шушы гамәлләрне" сүзләрен "2. Шушы гамәлләрне" сүзләренә алмаштырырга;

10) 3.11 статьяда:

а) беренче өлештә "Балаларның" сүзен "1. Балаларның" сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә "Шул ук гамәлләрне" сүзләрен "2. Шул ук гамәлләрне" сүзләренә алмаштырырга;

11) 3.14 статьяда:

а) беренче өлештә "Мәдәни-тамаша" сүзләрен "1. Мәдәни-тамаша" сүзләренә алмаштырырга, "ел дәвамында" сүзләрен "2. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган гамәлләрне ел дәвамында" сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә "Трибунага" сүзен "3. Трибунага" сүзләренә алмаштырырга, "ел дәвамында" сүзләрен "4. Әлеге статьяның 3 өлешендә каралган гамәлләрне ел дәвамында" сүзләренә алмаштырырга;

12) түбәндәге редакциядә 3.15 статья өстәргә:

"3.15 статья. **Җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнү**

1. Җәмәгать урыннарында гражданнарга хәер сорау, күрәзәлек итү, сексуаль характердагы хезмәт күрсәтүләр максатыннан ялыктыргыч бәйләнеп, җәмәгать тәртибен бозган өчен –

кисәтү ясала яисә йөз сумнан алып биш йөз сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

2. Ел дәвамында шул ук гамәлләрне кабат кылган өчен –

өч мең сумнан алып биш мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.”;

13) 4.1 статьяда:

а) беренче өлештә “Мәдәни” сүзен “1. Мәдәни” сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә “Шул ук гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган (гамәл кылмаган) өчен” сүзләрен “2. Шул ук гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган өчен” сүзләренә алмаштырырга;

14) 4.2 статьяда:

а) беренче өлештә “Җирле” сүзен “1. Җирле” сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә “Шул ук гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган (гамәл кылмаган) өчен” сүзләрен “2. Шул ук гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган өчен” сүзләренә алмаштырырга;

15) 4.3 статьяда:

а) беренче өлештә “Татарстан Республикасы” сүзләрен “1. Татарстан Республикасы” сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә “Татарстан Республикасы” сүзләрен “2. Татарстан Республикасы” сүзләренә алмаштырырга;

16) 4.4 статьяда:

а) беренче өлештә “Муниципаль” сүзен “1. Муниципаль” сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә “Муниципаль” сүзен “2. Муниципаль” сүзләренә алмаштырырга;

17) 5.6 статьяда:

а) беренче өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Социаль йөрү документы булган пассажирны йөртүгә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм җир өсте электр шәһәр транспортының тышкы яисә эчке ягында бу категориягә караган гражданнарны йөртүгә язма рәвештә тыю урнаштырып йә тиешенчә рәсмиләштерелгән йөрү документларын кабул итүдән йөртүче һәм (яисә) кондуктор баш тартып, шулай ук йөртүдән сүз белән тыеп, физик каршылык күрсәтеп яисә социаль йөрү документы булган пассажирның транспортта йөрүенә тоткарлык тудыра торган бүтән гамәлләр кылып каршы төшүгә юнәлтелгән гамәл өчен – ”;

б) икенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

18) 7.1 статьяда “3.13, 3.14” саннарын “3.13 – 3.15” саннарына алмаштырырга;

19) 7.2 статьяда:

а) беренче өлештә “Татарстан Республикасында” сүзләрен “1. Татарстан Республикасында” сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән орган исеменнән түбәндәгеләр карый:”;

1 пунктта “башлыгы” сүзен “җитәкчесе” сүзенә алмаштырырга;

2 пунктта “башлыклары” сүзен “җитәкчеләре” сүзенә алмаштырырга;

20) 7.3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7.3 статья. **Татарстан Республикасында дәүләт экологик күзәтчелеген гамәлгә ашыра торган органнар**

1. Татарстан Республикасында дәүләт экологик күзәтчелеген гамәлгә ашыра торган органнар әлеге Кодексның 3.1 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карый.

2. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән органнар исеменнән түбәндәгеләр карый:

1) табигатьне саклау буенча Татарстан Республикасы баш дәүләт инспекторы, аның урынбасарлары;

2) табигатьне саклау буенча Татарстан Республикасы өлкән дәүләт инспекторлары;

3) табигатьне саклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекторлары;

4) хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү мохитен саклау, торгызу һәм алардан файдалану буенча Татарстан Республикасы баш дәүләт инспекторы, аның урынбасары;

5) хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү мохитен саклау, торгызу һәм алардан файдалану буенча Татарстан Республикасы өлкән дәүләт инспекторлары.”;

21) 7.5 статьяда:

а) беренче өлештә “Мәдәни” сүзен “1. Мәдәни” сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән орган исеменнән түбәндәгеләр карый:”;

2 пунктта “җирле” сүзен “территориаль” сүзенә алмаштырырга;

22) 7.6 статьяда:

а) беренче өлештә “Пассажирлар” сүзен “1. Пассажирлар” сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән орган исеменнән түбәндәгеләр карый:”;

23) 7.7 статьяда:

а) беренче өлештә “Татарстан Республикасы” сүзләрен “1. Татарстан Республикасы” сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән орган исеменнән түбәндәгеләр карый:”;

24) 8.1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“8.1 статья. **Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар**

1. Әлеге Кодекста каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне шушы Кодексның 7.2, 7.3, 7.5 – 7.7 статьялары нигезендә тиешле орган компетенциясе чикләрендә административ хокук бозулар турындагы эшләрне карауга вәкаләтле органнарның вазыйфаи затлары төзи.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очраклардан тыш, шушы Кодексның 2.8 статьясы, шулай ук 2.4, 2.5, 3.2, 3.8, 3.10 (гражданнарга карата), 3.11, 3.14, 3.15 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне эчке эшләр органнарының вазыйфаи затлары төзи.

3. Әлеге Кодексның 2.1 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне (телләр турында Татарстан Республикасы законнарын гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен бозуга яисә гражданнарның мәгариф өлкәсендә телгә караган хокукларын чикләүгә китергән бозуларга кагылышлы) түбәндәгеләр төзи:

1) Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры, аның урынбасарлары;

2) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының структур бүлекчәләре җитәкчеләре.

4. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очраклардан тыш, шушы Кодексның 5.1, 5.2, 5.6 статьяларында (муниципальара пассажир йөртүләргә кагылышлы), шулай ук 2.1 статьясында (юл күрсәткечләрен һәм башка күрсәткечләрне, билгеләмәләрне рәсмиләштергәндә һәм урнаштырганда телләр турында Татарстан Республикасы законнары таләпләрен үтәмәү өлешендә) каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне Татарстан Республикасы Транспорт һәм юллар хуҗалыгы министрлыгының структур бүлекчәләре вазыйфаи затлары төзи.

5. Әлеге Кодексның 2.2, 2.6, 2.7 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне түбәндәгеләр төзи:

1) Татарстан Республикасы юстиция министры, аның урынбасарлары;

2) Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының структур бүлекчәләре белгечләре.

6. Әлеге Кодексның 2.3 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле

вәкилнең эшчәнлегенә кагылышлы), Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эшчәнлегенә кагылышлы) төзи.

7. Әлеге Кодексның 2.11 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең вазыйфаи затлары төзи.

8. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очраклардан тыш, шушы Кодексның 3.1 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү мохитен саклау, торгызу һәм алардан файдалану буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекторлары төзи.

9. Әлеге Кодексның 3.6 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге норматив хокукый актлары белән билгеләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать байлыклары министрлыгының вазыйфаи затлары төзи.

10. Әлеге Кодексның 3.10 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне (вазыйфаи һәм юридик затларга карата) түбәндәгеләр төзи:

1) Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры, аның урынбасарлары;

2) Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының структур бүлекчәләре һәм аның территориаль органнары белгечләре.

11. Әлеге Кодексның 3.13 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының һәм аның территориаль органнарының вазыйфаи затлары төзи.

12. Әлеге Кодексның 4.3 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының вазыйфаи затлары төзи.

13. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очраклардан тыш, шушы Кодексның 6.1 – 6.3 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне түбәндәгеләр төзи:

1) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының структур бүлекчәләре җитәкчеләре, аларның урынбасарлары;

2) Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе, Рәис урынбасары, аудиторлары һәм инспекторлары.

14. Әлеге статьяның 1, 2, 4, 5, 9, 13 өлешләрендә каралган очраклардан тыш, шушы Кодексның 2.6, 2.7, 3.2, 3.6, 4.2, 5.1, 5.2, 6.1 – 6.3 статьяларында (җирле бюджет акчалары өлешендә), шулай ук 2.12, 2.13, 3.3 – 3.5, 3.7, 4.4, 5.6 статьяларында (тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль йөртүләргә карата) каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары төзи.

15. Җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары әлеге статьяның 14 өлешендә каралган очракларда административ хокук бозулар турында беркетмәләрне җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе яисә Татарстан

Республикасы тарафыннан тапшырылган контроль (күзәтчелек) вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда, шулай ук муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда төзи.

16. Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә әлеге статья нигезендә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге, бурычлары һәм функцияләренә ярашлы рәвештә, вәкаләтле органнар тарафыннан, шулай ук, тиешле дәүләт вәкаләтләре бирелгән очракта, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.”.

**2 статья**

“Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында” 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2013, 9 февраль), “2.7” саннарыннан соң “, 2.12, 2.13,” саннарын өстәп, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013елның 18 июне
№ 47-ТРЗ